ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

22 декабрь 2017 ел

№ 8052

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге милкендәге җир участоклары белән яңадан бүлү нәтиҗәсендә шәхси милектә булган җир участокларының мәйданы арткан өчен түләү күләмен билгеләү тәртибен билгеләү турында

Россия Федерациясе Җир кодексының 39.28 маддәсендәге 5 пунктның 3 пунктчасы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль закон, Шәһәр Советының 2007 елның 4 октябрендәге 25/5 нче карары белән расланган Яр Чаллы шәһәренең муниципаль мөлкәтен биләү, файдалану, аның белән идарә итү һәм эш йөртү тәртибе турында нигезнамәнең 12 пунктының 9 пунктчасы нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге милкендәге җир участоклары белән яңадан бүлү нәтиҗәсендә шәхси милектә булган җир участокларының мәйданы арткан өчен түләү күләмен билгеләү тәртибен кушымтада каралганча билгеләргә.

2. Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы Л.Р. Гыйззәтуллинга әлеге карарны «Челнинские известия» газетасында бастыруны, «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм шәһәрнең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы Л.Р. Гыйззәтуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

Р.Ә. Абдуллин

Башкарма комитеның
2017 елның 22 декабрендәге
8052 нче карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге милкендәге
җир участоклары белән яңадан бүлү нәтиҗәсендә
шәхси милектә булган җир участокларының мәйданы арткан өчен
түләү күләмен билгеләү тәртибе

1. Әлеге Тәртип Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге милкендәге җир участоклары белән яңадан бүлү нәтиҗәсендә шәхси милектә булган җир участокларының мәйданы арткан өчен түләү күләмен (алга таба – түләү күләме) билгеләү кагыйдәләрен регламентлаштыра.

2. Түләү күләме Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге милкендәге җир участокларына карата милекче вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы шәһәр Башкарма комитеты тарафыннан исәпләнә.

3. Түләү күләме Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге милкендәге җир участогының шәхси милектәге җир участоклары белән яңадан бүлү нәтиҗәсендә шәхси милеккә бирелергә тиешле мондый җир участогы өлеше мәйданына пропорциональ рәвештә исәпләнгән кадастр бәясенең 15 проценты күләмендә билгеләнә, әлеге Тәртипнең 4 пунктында каралган очрактан тыш.

4. Муниципаль ихтыяҗлар өчен булдырылырга тиешле җир участокларын алга таба алу максатларында җир участоклары яңадан бүленгән очракта, түләү күләме җир участокларын яңадан бүлү нәтиҗәсендә шәхси милеккә бирелергә тиешле Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге милкендәге җир участогы өлешенең бәяләү эшчәнлеге турындагы законнарга таянып билгеләнгән базар бәясе нигезендә билгеләнә.

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе

Г. К. Әхмәтова